Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-6**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 05 марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 31 августындагы XI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 31 августындагы XI-3 номерлы Карарының 3 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

“3.Тәгаенләргә: әлеге карар

рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә, Нигезләмәнең үз көченә 2023 елның 1 гыйнварыннан керәчәк 4 бүлегеннән гайре;

аның гамәлдә булуы 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.”.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 31 августындагы XI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек белән тулыландырырга:

“5. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү

5.1. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү муниципаль җир контроле өлкәсендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеге һәм эффектлылыгы күрсәткечләре системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге һәм эффектлылыгы күрсәткечләре системасына

кирә:

1) муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре;

2) муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре.

5.3. Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре муниципаль районның вәкиллекле органы карары белән раслана.

5.4. Контроль орган ел саен, 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, муниципаль җир контроле турында доклад әзерләүне гамәлгә ашыра.

5.5. Муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, индикатив күрсәткечләр әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән.

5.6. Доклад әзерләүне оештыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә йөкләнә.”.

2.2. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 3 нче Кушымта белән тулыландырырга:

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы территориясендә
муниципаль җир контроле турындагы
Нигезләмәгә кушымта №3

**Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм индикатив күрсәткечләре**

| Төп күрсәткечләр | Максатчан кыйммәтләр |
|---|---|
| Җир законнарын бозуларның ачыкланган санынннан бетерелгән бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең проценты | 0% |
| Контроль чараларның бетерелгән нәтиҗәләренең проценты | 0% |
| Административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |

| | |
|---|---|
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында чыгарылган суд карарлары проценты | 95% |
| Муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми саныннан административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның проценты | 0% |

Муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре исемлеге:

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү чаралары саны;

2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

4) хисап чорында хезмәттәшлек белән үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән КНМның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү буенча контроль чаралар саны ;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән тикшерү чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;

11) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына һәр хәвеф-хәтәр категориясе буенча хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;

16) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

17) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында судка кадәр тәртиптә контрольлек итүче затлар тарафыннан бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында тикшерү органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләрнең саны;
20) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән,аларны карау йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгару турында яисә контроль органнарның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләрнең саны;
21) хисап чорында контроль органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;
22) хисап чорында контроль органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;
23) хисап чорында муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) юкка чыгарылган контроль чаралар саны.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Үткәрелгән чаралар параметрларын сыйфатлаучы индикатив күрсәткечләр | | | | |
| 1.1. | Планлы (рейд) биремнәренең (карауларның) үтәлеше | Врз = (РЗф / РЗп) х 100 | Врз - Планлы (рейд) биремнәренең (карауларнын) үтәлеше %<br>РЗф – Үткәрелгән планлы (рейд) биремнәре (караулары) саны (бер.)<br>РЗп - Расланган планлы (рейд) биремнәре (караулары) саны (бер.) | 100% | Расланган планлы (рейд) биремнәре (караулары) |
| 1.2. | Планнан тыш тикшерүләрнең үтәлеше | Ввн = (Рф / Рп) х 100 | Ввн - Планнан тыш тикшерүләрнең үтәлеше<br>Рф – планнан тыш үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.)<br>Рп - планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен | 100% | Контроль органга килеп ирешкән хатлар һәм шикаятьләр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | күрсәтмәләр саны (бер.) | | |
| 1.3. | Нәтиҗәләренә шикаять бирелгән тикшерүләр өлеше | Ж х 100 / Пф | Ж – шикаятьләр саны (бер.)<br>Пф – үткәрелгән тикшерүләр саны | 0% | |
| 1.4. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган тикшерүләр өлеше | Пн х 100 / Пф | Пн – дөрес түгел дип табылган тикшерүләр саны (бер.)<br>Пф – үткәрелгән тикшерүләр саны(бер.) | 0% | |
| 1.5. | Милекче булмау сәбәпле үткәрелмәгән планнан тыш тикшерүләр өлеше һ. б. | По х 100 / Пф | По - тикшерелүче зат булмау сәбәпле үткәрелмәгән тикшерүләр (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны(бер.) | 30% | |
| 1.6. | Планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында прокуратурага килештерүгә җибәрелгән гаризаларның өлеше (аларны килештерү кире кагылган) | Кзо х 100 / Кпз | Кзо - килештерү кире кагылган гаризалар саны (бер.)<br>Кпз – килештерүгә бирелгән гаризалар саны | 10% | |
| 1.7. | Нәтиҗәләре буенча материаллары карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр өлеше | Кнм х 100 / Квн | К нм - вәкаләтле органнарга җибәрелгән материаллар саны (бер.)<br>Квн - ачыкланган бозулар саны (бер.) | 100% | |
| 1.8. | Үткәрелгән | | | Данә | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | профилактик чаралар саны | | | | |
| 2. | Файдаланылган хезмәт ресурслары күләмен сыйфатлаучы индикатив күрсәткечләр | | | | |
| 2.1. | Штат берәмлекләре саны | | | Кеше | |
| 2.2. | Муниципаль контроль органы хезмәткәрләренә контроль чаралар йөкләнеше | Км / Кр= Нк | Км - контроль чаралар саны (бер.)<br>Кр - муниципаль контроль органы хезмәткәрләре саны (бер.)<br>Нк - 1 хезмәткәргә йөкләнеш (бер.) | | |

“

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов